РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» апрель 2024 ел г. Альметьевск № 1560

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2026 елларга Әлмәт муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программаны раслау турында» 2023 елның 12 декабрендәге 7857 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Төзәтүләр тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2026 елларга Әлмәт муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программаны раслау турында» 2023 елның 12 декабрендәге 7857 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтада:

- Программа паспортының «Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме җирле бюджет хисабына 1790,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны гамәлгә ашыру еллары буенча:<br>2024 ел - 930 мең сум;<br>2025 ел - 430 мең сум;<br>2026 ел - 430 мең сум.<br><br>Искәрмә: *Финанслау күләме фаразлау характерында һәм тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. |

- «Программаны ресурслар белән тәэмин итүне җайга салу» 4 бүлегенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслауның гомуми күләме 1790,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны гамәлгә ашыру еллары буенча:

2024 ел - 930 мең сум;

2025 ел - 430 мең сум;

заказ № 1-851

2026 ел - 430 мең сум.»;

- 2024-2026 елларга Әлмәт муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программа кушымтасының «Террорчылыкны һәм экстремистлык күренешләрен профилактикалау һәм кисәтү» дигән 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.28. Муниципаль милектәге кешеләр күпләп була торган объектларда металл декторлар сатып алу һәм урнаштыру | ТР ӘМР БК | 2024 | ӘМР бюджеты | 500,0 | 0,0 | 0,0 |

- «Программа буенча барлыгы:» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| Программа буенча барлыгы: | 930,0 | 430,0 | 430,0 |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов